СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

28.05.2021 № 11/2

На № __________ от ______________

# КАРАР

**Тукай муниципаль районы территориясендә яшүсмерләр җинаятьчелеге һәм балигъ булмаганнарга карата җинаятьчелек торышы, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын кисәтү системасы органнары тарафыннан күрелә торган чаралар турында**

«Тукай муниципаль районы территориясендә яшүсмерләр җинаятьчелеге һәм балигъ булмаганнарга карата җинаятьчелек торышы, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын кисәтү системасы органнары тарафыннан күрелә торган чаралар турында» мәгълүматны тыңлап, фикер алышканна соң, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Мәгълүматны игътибарга алырга.
2. Район Башкарма комитетына, яшүсмерләр арасында җинаятьчелекне булдырмау максатыннан, спорт һәм мәдәни юнәлештәге учреждениеләр эшчәнлеген тәэмин итәргә.
3. Авыл җирлекләре Башлыкларына, балигъ булмаганнарга карата җинаятьлекне булдырмау максатыннан, имин булмаган гаиләләрне ачыклау буенча эшне көчәйтергә, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча иҗтимагый комиссияләрнең эшчәнлеген активлаштырырга тәкъдим итәргә.
4. Тукай муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясенә:

- комиссиянең күчмә утырышларын елына кимендә 2 тапкыр уздыруны планлаштырырга;
- җәмәгать тәрбиячеләре эшен көчәйтергә, «Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру кысаларында эшчәнлекләре турында тыңлауларны практикага кертеп җибәрергә;

5. Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай муниципаль районы буенча бүлегенә гражданнарны балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия утырышына мәҗбүри китерү буенча эшне оештырырга тәкъдим итәргә, бүлек хезмәткәрләре арасыннан җәмәгать тәрбиячеләре вазыйфасына кандидатуралар тәкъдим итү буенча рекомендация бирергә.

6. «Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә җәйге ял чорында хезмәт һәм ял лагерьлары, ял мәйданчыклары эшчәнлеген тәэмин итәргә; хәвеф төркемендәге балалар һәм яшүсмерләр белән мәдәни-ял, физкультура-сәламәтләндерү һәм туристик эш алып барырга.

7. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлегенә авыр тормыш хәлендә булган балаларның ялын, сәламәтләндерүен һәм мәшгульлеген оештыру буенча эш алып баруны тәкъдим итәргә.

8. Яр Чаллы шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең Тукай районы буенча филиалына җәйге каникуллар вакытында 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаганнарны эшкә урнаштырырга, социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдәге балаларга аерым игътибар бирергә тәкъдим итәргә.

9. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Ф.М. Камаев